СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
Арского муниципального района
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦПИАЛЬ РАЙОНЫ
УРНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты,
Урнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

# КАРАРЫ

**от «25» февраля 2022 года** **N 37**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советының 2021 елның 02 декабрендәге 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 02.12.2021 ел, № 33 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 190 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннардан алынган продуктларның ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, әйләнә-тирә мохитне хайваннардан алынган калдыклар белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактик чаралар үткәрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Габделхаков В.Р.